**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 30.01.2023** **№ 155**

# Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләреннән Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны 2023 елда тукландыруны оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән Биектау муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучылары өчен 2023 елда кайнар ризык белән тукландыру оештырырга.

Белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануы чыгымнарын финанслауга түбәндәгеләрне җибәрергә:

- җирле бюджеттан 1-11 сыйныф укучылары өчен ике тапкыр тукландыру оештыруга көненә 38,00 сум.

2. Укучыларны кайнар тукландыруны оештыру өчен җаваплылыкны гамәлдәге законнар нигезендә мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Арча, Биектау районнарында территориаль бүлегенә (Салкова Э.В.) Биектау муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру өчен китерелә торган азык-төлек продуктлары сыйфатын даими контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә; укучыларны тукландыруны мөстәкыйль оештыручы учреждениеләрдә тукландыруны оештыруның җитештерү контролен (шул исәптән лаборатория тикшеренүләрен) гамәлдәге законнар нигезендә тулы күләмдә тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУнә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ сметасы буенча билгеләнгән нормативлар нигезендә укучыларны тукландыруга максатчан чараларны үз вакытында финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма

комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (Әхмәтҗанов Н.К.) кайнар тукландыруны оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалануны, исәпкә алуны, мәктәп яны участоклары продукциясе исәбеннән ассортиментны һәм туклану рационын баетырга тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo. tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин